РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Простинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423553, Нижнекамский район,
с. Прости, ул. Школьная, 8

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Прости авыл жирлеге
Советы

423553, Түбән Кама районы,
Прости авылы, Мэктэп урамы, 8

тел./факс (8555) 44-98-35, электронный адрес: Prostinskoe.sp@tatar.ru, сайт: www. prostinskoe-sp.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 25 июленнән № 12

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Прости авыл җирлеге Советының
2014 елның 30 октябрендәге
26 номерлы карарына
үзгәрешләр кертүтурында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Прости авыл җирлеге Советы карарбирә:

1. Прости авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 октябрендәге 26 номерлы карары белән расланган «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 7 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) белешмә бирү чорына кадәрге календарь ел эчендә (алга таба – хисап чоры) үзе, аныңире (хатыны) һәм (яки) балигъ булмаган балаларыбашкарган җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыймммәтле кәгазьләр, акцияләр (катнашу өлеше, оешмаларның устав (склад) капиталларында пайлар) алуда һәр килешү буенча үзенең чыгымнары, шулай ук аның ире (хатыны) һәм (яки)

балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматлар, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге өч ел эчендә әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм алар хисабына алыш-бирешләр башкарылган акча алу чыганаклары турында.».

1.2. Нигезләмәнең 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә тәкъдим ителгәнҗир кишәрлеген, башка күчемсез милек объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (катнашу өлеше, оешмаларның устав (склад) капиталларында пайларны) сатып алу буенчаалар хисабына алыш-бирешләр башкарылган (алыш-биреш башкарылган) акча алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елда муниципаль вазыйфаяисә муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштыручы (биләүче) затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, федераль законнар нигезендә урнаштырыла.».

1.3. Нигезләмәнең 16 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктындагы «в» пунктчасында каралган мәгълүматларны тапшыру буенча бурычны муниципаль вазыйфаны биләче зат тарафыннан башкармау хокук бозу булып тора. Күрсәтелгән хокук бозуны кылган зат биләгән вазыйфасыннан билгеләнгән тәртиптә азат ителергә тиеш.

Муниципаль вазыйфаны биләүче затның чыгымнарын, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын тикшерүне гамәлгә ашыру барышында әлеге зат чыгымнары, шулай ук аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары гомуми керемнәренә туры килмәүне раслаучы хәлләр ачыкланган очракта, чыгымнарны тикшерүне гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә алынган материаллар ул тәмамланганнан соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына җибәрелә.

Муниципаль вазыйфаны биләүче затның чыгымнарын, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын тикшерүне гамәлгә ашыру барышында җинаять, административ яки башка хокук бозу билгеләре ачыкланган очракта, чыгымнарны тикшерүне гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә алынган материаллар ул тәмамланганнан соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан дәүләт органнарына аларның компетенцияләре нигезендә җибәрелә».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Простинского сельского поселения
ИНН 1630003186
ОГРН 1021602512392

Прости авыл җирлеге башлыгы Д.А. Бәдәртинов